

Һәр шәхес vзенчәлекле һәм кабатланмас. Шушы vзенчәлекләр яна мәктәп шартларында ижади фикер йортvче педагогларны укучыларга белем бирv генә тvгел, ә аларнын табигать тарафыннан бирелгән сәләтләрен дә vстерvне максат итеп куя. Укучы бала мәктәпкә белем артыннан гына тvгел, торле яклап сәләтен vстерер очен дә килә.Укытучыдан сәләтле балаларнын кvнелен анлау, аларнын vсешенә коч-куәт бирерлек эшләр башкару, индивидуаль якын килv таләп ителә.
Ләмберә районы мәктәпләрендә сәләтле балалар белән якыннан килеп эш итә укытучылар. Ләмберәнен икенче гомуми белем бирvче урта мәктәбенен бишенче сыйныфында ике сәләтле Адель укый; берсе - Ямбаев, икенчесе - Смакаев. Мәктәп «йолдызчыклар»ы  алар.      Адель Ямбаев радиоэлектроника белән мавыга. «Яшьләр ижаты» дигән респуб-лика конкурсында лаеклы беренче урын яулаган! Районнын балалар ижаты Йорты тvгәрәк житәкчесе Айса Шамир улы Кадыркаев белән  Адель супервизорда аккумулятор зарядкасынын идарә модулен модельләштергәннәр. Яшь Кулибин эченә кертеп эретеп ябыштыру аппараты – микросхема – супервизор, текстолит платасына башка электроника детальләре белән монтажлап куйган. Автомобиль аккумуляторын корып кую очен кулланыла. Укучыларнын сәләтен ачыклау, индивидуаль якын килеп, югары нәтижәләргә ирешерлек итеп кызыксындыру Айса Шамир улы Кадыркаевнын хезмәт девизы.
Ә Адель Смакаевны кызыксындырган олкә - әдәбият. Кvпторле конкурсларда катнаша ул. Кvнеленен бер почмагында жинv булса да, кем уйлаган шундый югарылыкка менәр дип: 20 май конне Кремльнен Колонналы залында «Сәләтле балалар - 2017»  Халыкара форумында тантаналы рәвештә ирешкән унышлары очен илнен киләчәге дип котларлар аны. Нәрсә очен дип сорарсыз? Адельнен әдәбият укытучысы Ольга Александровна Приказчикова, сәләтле балаларынын кvнелен анлый, аларнын vсешенә коч-куәт бирерлек эшләр башкара, индивидуаль якын килеп эшли. Ул «Әдәбият салоны»ндагы «Глаголом жечь сердца людей» номинациядә катнашырга теләк белдереп, интернет конкурс-ка теркәлгән. Темасы да гади генә тvгел бит. Форумнын девизы да катлаулы: «Юллар - бормалы, дореслек - туры». Әмма Ольга Александровна житәкчелегендә Адель белән әзерләнгән реферат, эссе, монолог һәм шигырь жюри әгъзаларына бик тә ошый һәм яшь авторга Гран-при бирергә карар чыгаралар. Шулай Адельга икенче турда катнашмый гына Мәскәvдәге форумда vзенен ижаты белән башкалар арасында ярышырга момкинчелек туган. Нәтижәдә - Россия буенча оченче лаеклы урын яулаган. Алда - яна ижади планнар, ә бvген Адельны Мәскәvдәге бvләкләv котә.
Әйтеп китәргә кирәк, Мәскәvдә vткән «Сәләтле балалар - 2017» Халыкара форумына

Россиянен торле почмакларыннан сәләтлеләр жыела. Шул исәптән, Мордовиянен дә торле район мәктәпләре укучылары катнашалар. Мәсәлән, Кадошкино гомуми урта мәктәбеннән биш бала форумда катнашып оч Гран-при яулаганнар: В. Кандрашина «Киемнәр модельләштерәбез» номинациясендә, Л. Юнязова - «Декоратив-кулланма сәнгать һәм халык ижаты» номинациясендә һәм Р. Кузнецов - «Яшь экологлар берләшмәсе» номинациясендә. «Сынлы сәнгать» номинациясендә К. Наумов лаеклы беренче урынны алган.
Балаларыбызнын сәләтен vcтерv остендә даими эшләгәч, унышлар кvренеп тора.

**Н.Хәлил**